**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

2019 елның 21 февраленнән №9-РС

# КАРАР

**Район Советының 2018 елның 12 ноябреннән №67-РС “Лаеш муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия турында”гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябреннән № 131-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга, Татарстан Республикасының 2011 елның 20 маеннан №26-ЗРТ “Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия турында”гы Законына ярашлы төстә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль район Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Район Советының 2018 елның 12 ноябреннән №67-РС “Лаеш муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия турында”гы Карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 һәм 2нче пунктларны яңа редакциядә бирергә:

“1. Лаеш муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия булдырырга.

2. Лаеш муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия составын расларга (1 кушымта).”

1.2. Лаеш муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия турындагы кагыйдәне көчен югалткан дип табарга.

2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Лаеш муниципаль районы рәсми сайтының Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).

3. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне район Советының социаль мәсьәләләр, ветераннар һәм яшьләр эшләре буенча комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**